| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03.2021 № 184

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга исәпкә куюу һәм Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү регламентының яңа редакциясен раслау турындагы 07.09.2020 ел, 707 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 07.09.2020ел, 707 номерлы карар белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктында «Йорт китабыннан өземтә (документ коммерция оешмалары тарафыннан бирелгән очракта) пунктчасында;» төшереп калдырырга (текстта кулланылган урыннардан төшереп калдырырга);

2.6 пунктта (*хакимият органнары карамагында булган белешмәләр*):

«Йорт кенәгәсеннән өземтә» яисә «Йорт кенәгәсеннән өземтә (әгәр документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән булса)» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгы яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар»;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

«5) Граждан хәле актларын теркәү органнары-14 яше тулмаган гариза бирүченең гаилә әгъзалары өчен бала туу турында таныклык;

6) Гариза бирүче һәм/яки аның гаилә әгъзалары өчен никах теркәү турында таныклык-гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

7) Граждан хәле актларын теркәү органнары - ата булуны тану турында таныклык;

8) Аерылышу турында таныклык-гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

9) Россия Пенсия фонды - опека һәм попечительлек турында мәгълүмат.».

3.4.1 пунктында (ведомствоара запрослар җибәрү):

«йорт кенәгәсеннән өземтәләр» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү белешмәләре» сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

«5) бала туу турында таныклык;

6) язылышу турында таныклык;

7) ата булуын раслау турында таныклык;

8) аерылышу турында таныклык;

9) опека билгеләү турында мәгълүмат.».

2.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: